ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МОНАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

28 ноябрь 2024 ел №151

«Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Монай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә туристлык салымын билгеләү һәм гамәлгә кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 33.1 бүлеге, «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә туристлык эшчәнлеге нигезләре турында» 1996 елның 24 ноябрендәге 132-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Монай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Монай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә 2025 елның 1 гыйнварыннан түләүгә мәҗбүри булган туристлык салымын билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Физик затларның вакытлыча яшәү өчен урыннар бирү буенча күрсәтелә торган хезмәт хакының процентларда түбәндәге салым ставкаларын өстәлгән бәягә салым һәм салым суммаларын исәпкә алмыйча билгеләргә:

2025 елда- 1 процент;
2026 елда - 2 процент;
2027 елда - 3 процент;
2028 елда - 4 процент;
2029 елда - 5 процент.

3. Салым түләүчегә Россия Федерациясе Салым кодексының 418.4 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән физик затның тиешле статусын раслый торган документлар бирү шартларында салым базасына вакытлыча яшәү буенча хезмәт күрсәтүнең бәясе кертелми.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http//pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatarstan.ru «Норматив документлар» бүлегендә бастырып чыгарырга.

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының финанс-бюджет мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Монай авыл җирлеге Советы рәисе Р.М.Кириллов